КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 21 октябрь г.Казань № 905

2025 елга Татарстан Республикасындагы авыл территорияләрендә гомуми торак мәйданының бер квадрат метры кыйммәтен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында торак шартларын яхшырту чараларында катнашучылар исемлекләрен төзү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү һәм авыл территорияләрендә торак төзүгә (сатып алуга) социаль түләү бирү турында таныклыклар бирү тәртибенең 19 пункты һәм Торак урыннары наемы шартнамәләре буенча торак алучы гражданнарның исемлекләрен төзү, раслау һәм аларга үзгәреш кертү тәртибенең 21 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга Татарстан Республикасындагы авыл территорияләрендә гомуми торак мәйданының бер квадрат метры кыйммәтен түбәндәгечә расларга:

торак урыны наемы шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзү (сатып алу) буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына субсидия күләмен исәпләү өчен 67,41 мең сум күләмендә;

Татарстан Республикасындагы авыл территорияләрендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының торак шартларын яхшырту чаралары кысаларында торак төзүгә (сатып алуга) социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 34,02 мең сум күләмендә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2023 елга Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына торак урыны наемы шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзү (сатып алу) буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтүгә субсидияләр күләмен исәпләп чыгару өчен Татарстан Республикасындагы авыл территорияләрендә гомуми торак мәйданының бер квадрат метры кыйммәтен раслау турында» 2022 ел, 14 октябрь, 1102 нче;

«2022 елга социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен Татарстан Республикасындагы авыл территорияләрендә гомуми торак мәйданының бер квадрат метры кыйммәтен раслау турында» 2022 ел, 21 октябрь, 1129 нчы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин